| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
| --- | --- | --- |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 26 декабрь № 992

г. Казань

Г.И.Усманов истәлеген мәңгеләштерү турында

Атаклы Совет партиясе һәм дәүләт эшлеклесе, КПССның Татарстан обкомы беренче секретаре (1982 – 1989 еллар) Гомәр Исмәгыйль улы Усманов истәлеген мәңгеләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең, Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең, Чистай муниципаль районының атаклы Совет партиясе һәм дәүләт эшлеклесе, КПССның Татарстан обкомы беренче секретаре Гомәр Исмәгыйль улы Усманов истәлеген мәңгеләштерү турындагы инициативаларын хупларга.

2. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына Г.И.Усмановка мемориаль такта эшләргә һәм Казан шәһәре, Большая Красная ур., 65 нче йорт адресы буенча урнашкан бина фасадына куярга, шулай ук Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетына тәкъдим итәргә.

3. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына Г.И.Усманов тормышы һәм эшчәнлеге турында «Секретарь ЦК Г.И.Усманов. Жизнь и «Моменты истины» китабын яңадан бастырып чыгаруны тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы белән берлектә, Г.И.Усмановка мемориаль такта эшләү һәм Г.И.Усманов тормышы һәм эшчәнлеге турында «Секретарь ЦК Г.И.Усманов. Жизнь и «Моменты истины» китабын яңадан бастырып чыгару өчен кирәкле чыгымнар суммасын билгеләргә.

5. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетына Г.И.Усманов исемен түбәндәгеләргә бирү турындагы мәсьәләләрне карарга тәкъдим итәргә:

Казан шәһәре Н.Ершов урамында Казан шәһәренең «Арча зираты» үзәк некрополе каршында урнашкан скверга;

Казан шәһәрендәге «Салават Күпере» торак комплексында яңадан төзелә торган урамга.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мәдәният һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2016\992.docx